«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында КАРАР

2020 елның 5 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә2 020 елның 02 һәм 03 ноябрендә гражданнар җыенының уздырылган этаплары нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«2021 елда үзара салым кертүгә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан ,ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

• Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Калинин ур., 1 йорт, Пионер ур., 3 йорт (вак таш һәм асфальт өслек салу, смета нигезендә килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) юлын ремонтлау.»

Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау протоколы нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 613 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә 325 кеше катнашкан .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 320 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 5 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын үткәрелгән ,гражданнар җыены нәтиҗәләрен -дөрес , дип танырга.

2.Түбәндәге сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан 2021 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

• Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Калинин ур., 1 йорт, Пионер ур., 3 йорт (вак таш һәм асфальт өслек салу, смета нигезендә килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) юлын ремонтлау.»

3. 2021 елда үзара салымны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан 300 (өч йөз) сум күләмендә кертергә, моңа ташламалы категорияләр (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлар) керми), һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

• Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Калинин ур., 1 йорт, Пионер ур., 3 йорт (вак таш һәм асфальт өслек салу, смета буенча килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) юлын ремонтлау.

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге башлыгы, гражданнар җыенында рәислек итүче

И. Т. Гыйниятов